ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

№ 1016 2018 елның 12 декабре

***Постановление*** **КАРАР**

Рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә административ регламентны раслау турында

Россия Федерациясенең 2003елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131 нче номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210 нчы номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт властеның башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында”гы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”гы 880 нче номерлы Карарына таянып, Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 2010 елның 25 ноябрендә кабул ителгән “Чистай муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында”гы 1564 нче номерлы Карары нигезендә Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы башкарма комитеты (“Чистай муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында”гы 25.11. 2010 елгы1564 нче

номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 03.02. 2012 елгы 69 нчы номерлы Карары редакциясендә)

**КАРАР БИРӘ:**

1. Кушымта нигезендә рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә административ регламентны расларга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарны үтәүгә контрольлек итүне Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И.Ф.Рәхимовка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
башкарма комитеты карары
белән расланган
_________№ _______

**Рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә административ регламент**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеге бирүче әлеге административ регламент (алга таба – Регламент) рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәтләр алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба-гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәтләр Чистай муниципаль районы районы башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба – Башкарма комитет).

Муниципаль хезмәтләрне башкаручы – Чистай муниципаль районының "Шәһәр төзелешен көйләү һәм инфраструктураны үстерү" муниципаль бюджет оешмасы (алга таба - Бүлек).

1.3.1. Башкарма комитет урнашкан урын: : ТР, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 126 нчы йорт.

Оешма урнашкан урын: ТР, Чистай шәһәре, К. Маркс урамы, 27 нче йорт.

Эш графигы: дүшәмбе, сишәмбе - 13.00тән 17.00 сәгатькә кадәр
Чәршәмбе, пәнҗешәмбе - 8.00дән 12.00 сәгатькә кадәр.
Җомга – кабул итүләр булмый
Шимбә, якшәмбе – ял көннәре

Ял итү һәм туклану вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре буенча билгеләнә.

Белешмәләр өчен телефон: 8 (84342) 5-14-15, 5-15-54.

Алдан язылу кирәкми.

Керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. Муниципаль районның рәсми сайты адресы "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә (алга таба –"Интернет" челтәре): (http://chistopol.tatarstan.ru)

1.3.3. Муниципаль хезмәт турындагы мәгълүматны алу мөмкинлекләре:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет биналарында урнашкан муниципаль хезмәтләр турындагы визуаль һәм текст мәгълүматларыннан торган мәгълүмати стендлар чаралары буенча.

2) муниципаль районның рәсми сайтындагы «Интернет» челтәре чаралары буенча (http://chistopol.tatarstan.ru);

3) Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatar.ru/);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) Бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта (Бүлектә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә –шәхсән яки телефон буенча;

язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ алымы белән) – почта буенча кәгазьдә, электрон формада электрон почта аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет биналарының мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4.Муниципаль хезмәтләр күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясенең 29.12.2004 елгы 190 нчы номерлы Шәһәр төзелеше кодексы Федераль законы (алга таба – РФның ШтК) (РФның законнар җыентыгы, 03.01.2005, №1 ( 1бүлек, 16 нчы маддә);

Россия Федерациясенең 25.10.2001 елгы 136 нчы номерлы Җир кодексы Федераль законы (алга таба – РФның ҖК) (РФның законнар җыентыгы, 29.10.2001, №44, 4147 нче маддә);

Россия Федерациясенең 17.11.1995 елгы 169 нчы номерлы “Россия Федерациясендә архитектура эшчәнлеге турында”гы Федераль законы (алга таба – РФның 169 нчы номерлы Федераль законы) (РФның законнар җыентыгы, 20.11.1995, №47, 4473 нче маддә);

06.10.2003 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131нче номерлы Федераль закон (РФның законнар җыентыгы, 06.10.2003, N 40, 3822 нче маддә).

27.07.2010 елда кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы номерлы Федераль закон ( алга таба -210нчы номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 нчы маддә)

Татарстан Республикасының 28.07.2004 елгы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45нче номерлы законы (алга таба – 45 нче номерлы ТР законы) ( Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004);

Чистай муниципаль районы Советы Карары белән расланган Чистай муниципаль районы башкарма комитеты турындагы 16.05.2012 елгы17/4 Нигезләмә белән (алга таба – БК турындагы нигезләмә);

Башкарма комитет җитәкчесенең 21.03.2006 елгы 106-р нчы номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән (алга таба – Кагыйдә).

Башкарма комитет җитәкчесенең 12.02.2013 елгы 73нче карары белән расланган Чистай муниципаль районының "Шәһәр төзелешен көйләү һәм инфраструктура үсеше" муниципаль бюджет оешмасы уставы белән (алга таба – Оешма турында устав)

РФ Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге "Торак төзелеше өлкәсендәге процедураларның тулы исемлеге турында"гы 403 нче номерлы карарының 23 нче пункты "Рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт бирү (Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары белән каралган очракларда кулланыла)".

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2014 елның 29 гыйнварендагы 32/1нче карары белән кабул ителгән "Чистай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге уставы белән.

1.5. Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза астында (алга таба - гариза) муниципаль хезмәтләр күрсәтү турындагы сорау дип аңлашыла (27.07.2010 елгы 210 нчы Федераль законның 2 нче пунктының 2 нче маддәсе). Гариза ирекле формада, Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк буенча яки стандарт бланкта тутырыла.

## 2. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү стандарты

| **Муниципаль хезмәтләр күрсәтү стандартына таләпләр исемлеге** | **Стандартка таләпләр эчтәлеге** | **Хезмәтне яки таләпне билгеләүче норматив акт** |
|---|---|---|
| 2.1 Муниципаль хезмәтләр исемлеге. | Рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт бирү | РФ ШтКның 40 нчы маддәсе |
| 2.2. Башкарма властҗның турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче органы исеме | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты; | |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | 1. Рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуга рөхсәт итү<br>2. Хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ ШтКның 40 нчы маддәсе |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итүнен зарурлыгын исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату вакыты, әгәр Россия Федерациясе законы тарафыннан аны туктату мөмкинлеге каралган булса. | Рөхсәт бирү турында яки баш тарту турында карар кабул итү -4[1] , рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча җәмәгать тикшерүләре һәм ачык тыңлаулар йомгаклары турында нәтиҗә кергән вакыттан.<br>Җәмәгать тикшерүләре һәм ачык тыңлаулар үткәрү турында муниципаль берәмлектә яшәүчеләргә хәбәр иткән көннән алып җәмәгать тикшерүләре һәм ачык тыңлаулар йомгаклары турында нәтиҗәне бастыру көненә кадәр булган срок муниципаль берәмлек уставы һәм (яки) муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә һәм ул бер айдан артмаска тиеш. | РФ ШтКның 40 нчы маддәсенең 5 нче өлеше<br><br>РФ ШтКның 39 нчы маддәсенең 7 нче өлеше |
| 2.5 Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яки башка | 1) әлеге административ регламентның 1 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча төзелгән гариза; | |

| | | |
|---|---|---|
| норматив-хокукый актлар нигезендә кирәк булган документларның тулы исемлеге, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәт, аларны гариза бирүче тәкъдим итәргә тиеш | 2) җир участогына хокукны раслаучы документлар, әгәр күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки алардагы белешмәләр) күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында булмаса;<br>3) җир участогының конфигурациясе, инженер-геологик яки башка характеристикалары төзелеш өчен уңайсыз булуын раслаучы документлар;<br>4) гариза бирүченең яки гариза бирүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ;<br>5) ышаныч язуы, әгәр дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать итсә. | |
| 2.6 Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәк булган документларның тулы исемлеге, алар дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында һәм аларны гариза бирүче тәкъдим итәргә хаклы.. | Ведомствоара үзараэлемтә кысаларында ясала:<br>1) рөхсәт сорала торган җир участогы өчен күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>2) рөхсәт сорала торган җир участогы белән ызандаш урнашкан җир участоклары өчен күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>3) ызандаш җир участокларында урнашкан капиталь төзелеш объектлары өчен күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>4) ызандаш җир участокларында урнашкан капиталь төзелеш объектларының өлешләре булып торган биналар өчен күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>5)юридик затлар өчен күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә ( әгәр дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап юридик зат мөрәҗәгать итсә). | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Норматив-хокукый актлар белән каралган очракларда килештерү кирәк булган дәүләт оганнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур подразделениеләре исемлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма власть органы тарафыннан гамәлгә ашырыла | Килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләр билгеләнмәгән. | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яисә баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату өчен сәбәпләр юк; дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләр:<br>1) әлеге административ регламентның 2.7нче пунктында күрсәтелгән документларның булмавы;<br>2) гариза әлеге административ регламентның 1.3нче пункты нигезендә гариза бирүчеләр даирәсенә кермәүче зат тарафыннан бирелгән;<br>3) комиссиянең идарәгә җибәргән каршы тәкъдимнәре;<br>4) шундый читкә чыгуларның аэродром янындагы территориядә урнашкан күчемсез милек объектларыннан файдалануны чикләүгә туры килмәве. | |
| 2.10 Муниципаль хезмәтләр күрсәткән өчен алына торган | Муниципаль хезмәт бушлай нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт пошлинасы яки башка түләүләр алу тәртибе, күләме һәм сәбәбе . | Рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар яки җәмәгать тикшерүләрен оештыру (алга таба - ачык тыңлаулар) белән бәйле чыгымнарны шундый рөхсәт алу белән кызыксынучы физик һәм юридик затлар каплый, бәя һәм түләү тәртибе башкарма комитет хакимиятенең норматив-хокукый акты белән билгеләнә. | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган түләүләр алу тәртибе, күләме һәм сәбәбе, алар шундый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны үз эченә алып | Тиешле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12 Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорауны биргән һәм шундый хезмәт нәтиҗәсен алган вакытта чиратта торуның максималь срогы | Чират булганда муниципаль хезмәт алуга гариза бирү – 15 минуттан артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы соравын теркәү срогы | Гариза кергәннән соң бер көн дәвамында | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Муниципаль хезмәтләрне күрсәтү янгынга каршы һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен тиешле җиһазлар, мәгълүмат стендлары булган зданиеләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз кереп-чыгуы тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә бер урыннан бер урынга күчеп йөрүе). | Кагыйдәләр |

| | | |
|---|---|---|
| | Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текст формасында һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтләрне алу мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Муниципаль хезмәтләрне алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>биналарының җәмәгать транспорты йөри торган зоналарда урнашуы;<br>кирәкле белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыручы биналарның җитәрлек санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәре мәгълүмат ресурсларында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәт алуга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларны биргәндә чиратлар булмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәтләр күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаятьләр булмау;<br>муниципаль хезмәтләр күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә әдәпсез, игътибарсыз | |

| | | |
|---|---|---|
| | мөнәсәбәтенә шикаятьләр булмау.<br>Муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында сорау биргәндә һәм муниципаль хезмәтләр нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазифаи затның һәм гариза бирүченең үзара элемтәсе бер генә тапкыр булу күздә тотыла.Үзара элемтәнең дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә. | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон формада бирү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтләрне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә ( алга таба – КФҮ), КФҮнең читтәге эш урыннарында күрсәткәндә консультация, документларны кабул итү һәм тапшыруны КФҮ белгече гамәлгә ашыра.<br>Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны район сайтында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында, КФҮдә алырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәтләр алу тәртибе турындагы консультацияне Интернет-кабул итү аша электрон формада яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында алырга мөмкин.<br>Әгәр закон тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны электрон формада бирү каралган булса, гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең ( функцияләрнең) Бердәм порталы (http:// www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

**3.Административ процедураларның составы, эзеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең читтәге эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

2) ведомствоара сорауларны формалаштыру һәм җибәрү;

3) комиссия тарафыннан гаризаны һәм документларны карау;

4) ачык тыңлаулар үткәрү һәм комиссия тәкъдимнәрен әзерләү;

5) шундый рөхсәтне бирү һәм шундый рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү;

6)гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.1.2 Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлләрнең эзлеклелек блок-схемасы 2 нче кушымтада.

3.2. Гариза бирүчегә консультация күрсәтү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хаклы.

Бүлек белгече гариза бирүче белән консультация үткәрә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәтләр алу өчен башка сораулар буенча һәм әгәр кирәк булса гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пункт белән урнаштырылучы процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультация.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1.Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы кеше аша муниципаль хезмәт күрсәтүләрен сорап язмача гариза бирә һәм Бүлеккә әлеге Регламентның 2.5 нче пункты нигезендә документлар тапшыра.

Электрон формада муниципаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза Бүлеккә электрон почта яки Интернет-кабул итү аша җибәрелә. Электрон формада кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2.Бүлекнең гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече түбәндәгеләрне башкара:

-гариза бирүченең шәхесен ачыклау;

-гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү ( ышаныч кәгазе буенча булса);

-әлеге Регламентның 2.5нче пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерү;

-тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка төзәтүләр булмаска тиеш).

Дәгъвалар булмаган очракта Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

-гаризаны кабул итә һәм махсус журналда терки;

-гариза бирүчегә документларны кабул итү тамгасы белән тапшырылган документларның күчермәләре исемлеген тапшыра, бирелгән керү номерын, муниципаль хезмәтне үтәү көне һәм вакыты турында белдерә;

-гаризаны Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләр булган очракта Бүлекнең гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече гариза бирүчегә гариза теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм аңа документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрне язма рәвештә аңлатып тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнүче процедуралар 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрелгән гаризаны кабул итү һәм теркәү яки гариза бирүчегә документларны кире кайтару.

3.3.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм гаризаны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнүче процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза

3.4.Ведомствоара сорауларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.4.1.Бүлек белгече хезмәт күрсәтү турындагы сорауларны электрон формада ведомствоара үзара электрон система чаралары буенча җибәрә:

1) Бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез милеккә хокук һәм аның белән башкарылган эшләргә өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркемгә аңлаешлы булырлык белешмә);

2) Җир участогының шәһәр төзелеше планы (территорияне планировкалау проекты һәм линияле объект төзүгә рөхсәт биргән очракта территорияне межалау проекты реквизитлары);

3)Рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгуны рөхсәт итә ( әгәр төзүчегә РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40 нчы маддәсе белән шундый рөхсәт бирелгән булса);

4)Тәңгәл килү сертификатларының бердәм реестрыннан белешмә;

5)Проект доументациясенә дәүләт экспертизасының уңай нәтиҗәсе.

Әлеге пункт нигезендә урнаштырыла торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: власть органнарына җибәрелгән сораулар.

3.4.2. Мәгълүматлар куючы белгечләр ведомствоара үзара электрон система аша кергән сораулар нигезендә соратыла торган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәк булган документ һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында белдерү җибәрәләр (алга таба – баш тарту турында белдерү).

Әлеге пункт белән билгеләнүче процедуралар ведомствоара сорауның документ яки мәгълүмат бирүче органга яки оешмага керү көненнән алып өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла, әгәр федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары тарафыннан ведомствоара сорауга җавап әзерләү һәм җибәрү сроклары билгеләнмәгән һәм федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән кабул ителмәгән булса.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (белешмә) яисә кире кагу турында белдерү.

3.5 Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү:

3.5.1.Теркәлгән гаризаның комиссиягә карарга керүе админисратив процедураны башлау өчен нигез булып тора;

3.5.2. Комиссия гаризаны алган вакыттан алып 1 календарь көн дәвамында аны түбәндәгеләр булу-булмауга тикшерә:

-гариза бирүче тапшырган документларның тулылыгының һәм комплектлылыгының әлеге административ регламентның 2.4 пунктына туры килүенә;

-дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать иткән затның әлеге административ регламентның 3.3.1 пункты белән билгләнгән гариза бирүчеләр даирәсенә туры килүенә;

-гаризада күрсәтелгән таләп ителүче читкә чыгуларның техник регламентка туры килүе.

3.5.3. Әгәр комиссия тарафыннан әлеге административ регламентның 2.4 пункты тарафыннан күрсәтелгән документлар күрсәтелмәгән яки тулы күләмдә күрсәтелмәгән һәм (яки) дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать иткән затның әлеге административ регламентның 3.3.1 пункты белән билгләнгән гариза бирүчеләр даирәсенә туры килмәве һәм (яки) таләп ителүче читкә чыгулар техник регламент таләпләренә туры килмәве ачыкланса, комиссия әлеге административ регламентның 3.4.3. пунктчасында күрсәтелгән срокта рөхсәт бирүдән баш тарту турында (кабул ителгән карарның сәбәбен күрсәтеп) тәкъдим әзерли һәм аларны идарәгә җибәрә.

Әгәр комиссия тарафыннан әлеге административ регламентның 2.4 пункты тарафыннан күрсәтелгән документлар тулы күләмдә күрсәтелгән булуы һәм (яки) дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать иткән затның әлеге административ регламентның 1.3 пункты белән билгләнгән гариза бирүчеләр даирәсенә туры килүе ачыкланса һәм таләп ителүче читкә чыгулар техник регламент таләпләренә туры килсә, комиссия әлеге административ регламентның 3.4.2. пунктчасында күрсәтелгән срокта рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү зарурлыгы турында тәкъдим әзерли һәм аларны идарәгә җибәрә;

3.5.4. административ процедура дәвамлылыгы (аны максималь үтәү срогы) – 1 календарь көн;

3.5.5. административ процедура нәтиҗәсе булып комиссиягә ачык тыңлаулар билгеләү зарурлыгы турында яки идарәгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдимнәр җибәрү тора.

3.6. ачык тыңлаулар уздыру һәм комиссиягә тәкъдимнәр әзерләү:

3.6.1. башкарма комитетка комиссиянең ачык тыңлаулар билгеләү зарурлыгы турындагы тәкъдиме керү административ процедура башлау өчен нигез булып тора.

3.6.2. башкарма комитет җитәкчесе комиссиядән ачык тыңлаулар билгеләү зарурлыгы турындагы тәкъдимне алганнан соң 1 календарь көн дәвамында ачык тыңлауларны билгели;

3.6.3. комиссия ачык тыңлаулар билгеләнгән көнне әлеге рөхсәт сорала торган җир участогы белән уртак чикләре булган җир участоклары хуҗаларына, әлеге рөхсәт сорала торган җир участогы белән уртак чикләре булган җир участокларында урнашкан капиталь төзелеш объектлары хуҗаларына, әлеге рөхсәт сорала торган капиталь төзелеш объектының өлеше булган биналар хуҗаларына ачык тыңлаулар үткәрү урыны, вакыты һәм максаты турында хәбәр җибәрә;

3.6.4. ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2014 елның 29 гыйнварендагы 32/1нче карары белән кабул ителгән “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге уставы, шулай ук 2018 елның 18 июлендәге 32/1 нче номерлы “Ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы (җәмәгать тикшерүләре”) Нигезләмәсе белән билгеләнгән тәртиптә уздырыла. Ачык тыңлаулар үткәрү турындагы карар район хакимиятенең норматив-хокукый актларны һәм башка рәсми мәгълүматны рәсми бастыру өчен билгеләнгән тәртиптә, кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә бастырылырга тиеш; ачык тыңлауларны үткәрү срогы аларны билгеләү көненнән алып шундый тыңлаулар йомгаклары турындагы нәтиҗәне бастыру көненә кадәр 30 календарь көннән артмаска тиеш;

3.6.5.Рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар йогаклары турындагы нәтиҗә нигезендә комиссия ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы нәтиҗә басылган вакыттан алып 7 календарь көн дәвамында рөхсәт бирү турында яисә шундый рөхсәт бирүдән баш тарту турында (сәбәбен күрсәтеп) тәкъдим әзерли һәм аны идарәгә җибәрә.

3.6.6. Административ процедураның дәвамлылыгы (аны үтәүнең максималь срогы) 42 календарь көн тәшкил итә.

3.6.7. Административ процедура нәтиҗәсе булып комиссиянең әлеге административ регламентның 3.6.5 пунктчасы белән билгеләнгән тәкъдимнәрне идарә начальнигына җибәрүе.

3.7. Шундый рөхсәтне бирү яки шундый рөхсәтне бирүдән баш тарту турында карар кабул итү:

3.7.1. архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигының комиссиядән әлеге административ регламентның 3.5.3 пунктчасының беренче

абзацында күрсәтелгән тәкъдимнәрне яки комиссиядән әлеге административ регламентның 3.6.5 пунктчасында күрсәтелгән тәкъдимнәрне алуы административ процедура башлау өчен нигез булып тора;

3.7.2. рөхсәт бирү турында карар кабул ителгән очракта башкаручы карар проектын әзерли;

3.7.3. рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта башкаручы рөхсәт бирүдән баш тарту турында белдерү проекты әзерли. Баш тарту турындагы белдерүдә мәҗбүри тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булган сәбәпләр күрсәтелә.

3.7.4. карар проектына яки баш тарту турында белдерү проектына башкарма комитет җитәкчесе имза куя һәм ул билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

3.7.5. административ процедураның дәвамлылыгы (аны үтәүнең максималь срогы) комиссия тәкъдимнәрен алган вакыттан 7календарь көн тәшкил итә.

3.7.6. административ процедура нәтиҗәсе булып рөхсәт бирү турында карар кабул итү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында кул куелган белдерү.

3.8.гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру

3.8.1 рөхсәт бирү турындагы боерык кабул итү яки баш тарту турында кул куелган белдерү административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

3.8.2 боерыкның яки баш тарту турындагы белдерүнең бер данәсе гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән кабул иткәннән соң 2 календарь көн эчендә җибәрелә;

3.8.3 дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкин:

архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегендә;

МФҮдә;

3.8.4 гариза бирүче (аның вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен МФҮгә яки архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә мөрәҗәгать итсә, белгеч түбәндәге гамәлләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый, шул исәптән шәхесен раслаучы документны тикшерә;

гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен тикшерә;

бирелергә тиешле документларны таба;

гариза бирүчене бирелә торган документлар исемлеге белән таныштыра;

гариза бирүчегә документлар журналга кул куеп тапшырыла.

3.8.5.Белгеч түбәндәге сәбәпләр буенча документлар алу өчен мөрәҗәгать иткән затка документлар бирүдән баш тарта:

мөрәҗәгать итүче шәхесне раслаучы документ күрсәтүдән баш тартса;

документлар алу өчен тиешле зат мөрәҗәгать итмәсә.

Әгәр гариза бирүче үзенә бирелә торган документлар исемлеге белән килешмәсә, документлар алганда кул куюдан баш тартса, белгеч хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен бирү журналында “Документларны алудан баш тартты” дигән тиешле билге куя һәм үз имзасы белән раслый.

3.8.6 Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен идарәдән МФҮ алган көннән 30 календарь көн дәвамында гариза бирүче аны алмаса, МФҮ белгече таләп ителмәгән

документларны идарәгә җибәрә, бер үк вакытта документларның идарәгә җибәрелүе һәм аларны аннан алырга мөмкин булуы турында гариза бирүчегә хәбәр итә.

3.8.7 Административ процедураның дәвамлылыгы (аны үтәүнең максималь срогы) 2 календарь көн;

3.8.8. Административ процедура нәтиҗәсе булып гариза бирүчегә рөхсәт бирү турындагы боерыкны яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы белдерүне тапшыру.

3.9. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен тапшыру

3.9.1 Бүлек белгече:

теркәүләр журналында рөхсәт бирү турындагы ( баш тарту турындагы) карарны терки;

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән ысулдан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, рәсмиләштерелгән рөхсәтне яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы хатны бирү көнен һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пункт нигезендә урнаштырылган процедуралар башкарма комитет җитәкчесе документларга кул куйган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.9.2. Бүлек белгече гариза бирүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән рөхсәтне бирелгән рөхсәтләр журналында имза куйдырып рөхсәт алу турында яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы хатны, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, бирә.

Әлеге пункт нигезендә билгеләнгән процедуралар гамәлгә ашырыла:

рөхсәт бирүне яки яки баш тарту турындагы хатны – чират тәртибендә гариза бирүче килгән көнне, 15минут эчендә;

баш тарту турындагы хатны почта аша җибәрү - әлеге Регламентның 3.5.3нче пунктчасында каралган процедура тәмамланган вакыттан бер көн дәвамында.

Процедура нәтиҗәсе: бирелгән рөхсәт яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат.

3.9.3 Муниципаль хезмәтне МФҮ аша күрсәтү.

3.9.4. Гариза бирүче муниципаль хезмәт алу өчен МФҮкә мөрәҗәгать итәргә хаклы.

МФҮ белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен башка мәсьәләләр буенча, кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультация.

3.9.5. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм МФҮкә әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә документалар тапшыра.

3.9.6. Гаризаларны кабул итүне алып баручы МФҮ белгече административ регламент нигезендә түбәндәгеләрне тормышка ашыра:

документлар кабул итү белән бәйле процедуралар;

кергән гаризаны һәм документларны теркәү;

документлар пакетын Бүлеккә җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.9.7. Бүлек белгече МФҮтән документларны алгач, әлеге регламентның 3.3-3.5 пунктлары белән каралган процедураларны башкара. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе МФҮгә җибәрелә.

3.3-3.5нче пунктлар белән билгеләнгән процедуралар әлеге регламент белән билгеләнгән срокта башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: МФҮгә җибәрелгән муниципаль хезмәт нәтиҗәсе.

3.9.8. МФҮ белгече кергән муниципаль хезмәт нәтиҗәсен терки һәм гариза бирүчегә хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт нәтиҗәсе кергән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кергән муниципаль хезмәт нәтиҗәсе турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

3.9.9. МФҮ белгече гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен имза куйдырып бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза бирүче килгән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән муниципаль хезмәт нәтиҗәсе.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм контрольдә тоту алымы

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедурасын үтәүгә тикшерү үткәрүне, җирле үзидарә органының вазифаи затлары эшенә (чара күрмәүләренә) карарлар әзерләүне ала.

Административ процедураларны үтәүне күзәтү өчен контроль алымнары булып торалар:

1) муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Проектларны визалау тикшерү нәтиҗәсе булып тора;

2) эш производстволарын алып баруга билгеләнгән тәртиптә тикшерүләр уздыру;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедурасын үтәүгә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының яртыеллык яки берьеллык эш планнары нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки гариза бирүченең төгәл бер мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндәге гамәлләрне кылуга контрольлек итү максатында Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча билгеләнгән административ процедуралар эшенең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыру, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшләрне оештыру өчен башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, шулай ук инфраструктураны үстерү бүлеге белгечләре җаваплы.

4.3. Агымдагы контрольне тормышка ашыручы вазифаи затларның исемлеге җирле үзидарә органының структур подразделениеләре турындагы нигезләмәләр һәм вазифаи регламентлар белән билгеләнә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланганда гаепле затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җавапка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен үзвакытында карамау өчен җавап тота.

Җирле үзидарә органының структур подразделениесе җитәкчесе (аның урынбасары) әлеге Регламентның 3нче бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне үзвакытында һәм (яки) тиешенчә башкармаулары өчен җавап тота.

Вазифаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кулланылучы (гамәлгә ашырылучы) карарлары һәм гамәлләре (чара күрмәүләре) өчен Закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә җавап тоталар.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүгә контроль муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы чаралары белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазифаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (эшләмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) дәгъва белдерү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәтләр алучылар муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органның вазифаи затына яисә муниципаль хезмәткәрнең гамәлләренә (чара күрмәүләренә) судка кадәрге (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерергә хаклылар.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең соравын теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлары белән каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә башка гамәлләрне, күрсәтмәләрне таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең, норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тарту нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары нигезендә кабул ителгән,Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар тарафыннан каралмаган булса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар белән каралмаганда, түләү таләп итү;

7) башкарма комитет, башкарма комитетның вазифаи затларының, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 27.07.2010елгы 210 нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешманың яки аның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда киткән хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуы. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм

гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса;

8) муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срокларын һәм тәртибен бозу;

9) әгәр туктату сәбәпләре федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары,Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар тарафыннан каралмаган булса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса;

10) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны (аларның булмаулары һәм (яки) дөрес булмаулары) таләп итү яисә 27.07.2010 елгы 210 нчы Федераль законның 7нче маддәсенең 1 өлешенең 4 нче бүлегендә каралган очраклардан кала, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

5.2. Гариза бирүчеләр шикаятьне нигезләү һәм карау өчен мәгълүмат һәм документлар алуга хокуклы.

5.3. Шикаять муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып торучы дәүләт властеның ( җирле үзидарә органы) ачык-хокукый берәмлеге булган тиешле органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне оештыручы), шулай ук 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмаларга язмача формада кәгазьдә һәм электрон формада бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәвенә) шикаять югарыгы органга ( әгәр ул булса) бирелә яисә ул булмаганда турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә ( чара күрмәвенә) шикаять әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә

бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә ( чара күрмәвенә) шикаять күпфункцияле үзәкне оештыручыга яисә Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары буенча вәкаләте булган вазифаи затка бирелә. 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә ( чара күрмәвенә) шикаять әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

Россия Федерациясе Хөкүмәте белән расланган Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 6нчы маддәсенең 2нче өлеше нигезендә төзелеш өлкәсендәге процедураларның тулы исемлегенә кертелгән шәһәр төзелеше мөнәсәбәтләре, процедуралары субъектлары булып торучы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының, яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм (яки) гамәлләренә ( гамәл кылмауларына) шундый затлар тарафыннан шикаять әлеге маддә белән билгеләнгән тәртиптә яисә Россиясе Федерациясенең монополиягә каршы законында билгеләнгән тәртиптә монополиягә каршы органга бирелергә мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә ( чара күрмәвенә) шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәк, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмалар, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәвенә) шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (эшләмәүләренә) шикаять белдерелгән хезмәт күрсәтүче орган, хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының исеме яки муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме ( соңгысы әгәр булса), яшәү урыны турында белешмә, шулай ук элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы (әгәр булса) һәм почта адресы, аның буенча гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять белдерү турында белешмә;

4) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең гариза бирүченең хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары һәм гамәлләре (чара күрмәүләре) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр. Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы (алар булганда) документлар яисә аларның күчермәләре.

5.5. Шикаятькә анда язылган шартларны раслаучы документлар булмаса яки алар шикаятькә беркетелмәгән булса, карар дәлилләрне (аларны раслау өчен доккументлар тәкъдим ителмәгән) исәпкә алмыйча гына кабул ителә.

5.6. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне оештыручыга, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмаларга яисә югарыгы органга (әгәр ул булса) кергән шикаять аны теркәгәннән соң унбиш эш көне дәвамында каралырга тиеш. Әгәр муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешма гариза бирүчедән документларны кабул итүгә яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартса яки шундый төзәтүләрнең срогын бозуга шикаять белдерелсә - аны теркәгәннән соң биш эш көне дәвамында.

5.7.Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтүче орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү формасында, гариза бирүчегә акчаны кире кайтару, әгәр акча алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, Чистай муниципаль районының норматив-хокукый актлары белән каралмаган булса;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта:

5.8. Карарны кабул иткән көннән соң килә торган көннән соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача формада һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән җавап җибәрелә.

Шикаятьне канәгатьләнерлек дип тапкан очракта гариза бирүчегә җавапта муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган бозуларны тиз арада бетерү максатында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешма тормышка ашыра торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китергән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм муниципаль хезмәт алу максатында гариза бирүчегә алга таба нәрсә эшләргә кирәклеге турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаятьне канәгатьләнерлек дип тапмаган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында аргументлаштырылган аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки шикаятьне карау буенча вәкаләтләре булган вазифаи затның, хезмәткәрнең җинаятьләре ачыкланса, тиз арада булган материаллар прокуратура органнарына җибәрелә.

1нче кушымта

**Рөхсәт бирү турында гариза Формасы**

Чистай муниципаль районы
башкарма комитеты
җитәкчесенә

______________________________
Төзүче
________________________

прописка буенча адрес__________________

______________________________

______________________________
почта индексы ____________________

телефон_____________________

**Гариза**

Түбәндәге адрес буенча урнашкан җир участогында рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә чыгарга рөхсәт бирүегезне сорыйм:

______________________________________________________________________

_________________________________________________________________

өлешендә:

җир участокларының чик (минималь һәм максималь) күләмнәре, шул исәптән аларның мәйданы:_____________________________________________

җир участоклары чикләреннән минималь аралар, биналарны, төзелешләрне, корылмаларны, урнаштыру урынын билгеләү максатында, алар чигендә биналар, төзелешләр, корылмалар төзү тыела:

______________________________________________________________
_

биналарның, төзлешләрнең, корылмаларның этажлар саны чиге яки биеклек чиге_____________________________________________________________

жир участогының суммар мәйданы кебек билгеләнгән жир участогы чикләрендәге төзүләрнең максималь проценты, жир участогының бөтен мәйданына карата төзелергә мөмкин:

башка күрсәткечләр:

жир участогы турында белешмә:
жир участогы мәйданы____________________________кв.м;
урнашкан урыны (адрес)____________________________________________________

жир участогыннан файдаланыла торган хокук төре

(милек иясе аренда, даими ( срооксыз) файдалану һ.б.

файдалануны чикләү һәм жир участогына чикләүләр салу:

гариза бирүче жир участогыннан файдалана торган хокукны раслаучы документ реквизитлары:

(исеме, номеры, бирү көне, бирүче орган)
кадастр номеры:

капиталь төзелеш объекты турында белешмә:
кадастр номеры: __________________________________________________________
күрсәтелгән жир участогының күләме шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән жир участогы күләмнәреннән кечерәк яисә күрсәтелгән жир участогының конфигурациясе,инженер-геологик һәм башка характеристикалары

(кирәклесенең астына сызарга) төзелеш өчен җайсыз, бу раслана:

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турындагы мәгълүматны почта яки электрон почта аша җибәрүегезне сорыйм, нәтиҗәне вәкаләтле органга бирергә

______________________________________________________________________

(җибәрү ысулын күрсәтергә)

| ____________ | ____________________________ | __________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | гариза бирүченең имзасы | имзаны расшифровкалау |

**Кушымта**
**(белешмә)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешенә контрольлек итүче вазифаи затларның реквизитлары**

**Чистай  муниципаль районы башкарма комитеты**

| Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (84342)5-10-84 | Chistay@tatar.ru |
| Бүлек начальнигы | (84342)5-15-65 | Chis.Arhitek@tatar.ru |
| Бүлек белгече | (84342)5-14-15 | Marat.Bibishev@tatar.ru |

**Чистай  муниципаль районы Советы**

| Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башлык | (84342)5-43-70 | Chistay@tatar.ru |

)